**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР** №18

III чакырылышның чираттан тыш утырышы | Урыссу ш.т.б. | “26” июнь 2018нче ел.

*Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәткәр булып эшләүчеләргә һәм даими нигездә муниципаль вазифаларны үтәүчеләргә тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгулары белән бәйле бер тапкыр түләнелә торган акчаны (поощрение) түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында*

Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июненнән булган “Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы” 50 санлы Законының 31 маддәсенә, “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы, Ютазы район Советы

Карар итте:

1.Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу белән бәйле бер тапкыр түләнелә торган акчаны муниципаль хезмәткәрләргә түләү һәм даими нигездә муниципаль вазифаларны башкаручыларга түләү тәртибе турында теркәлгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2011 елның 13 маеннан булган “Ютазы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезләмәне раслау турында”гы 19 санлы Карарын көчен югалткан дип исәпләргә.

3.Әлеге Карар 2018 елның 1 апреленнән үз көченә керде.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән бергә эшләү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Ютазы район Советы Рәисе Р.М. Нуриев.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының
2018 елның “_” июненнән булган
Карары белән расланды

**Ютазы муниципаль районында тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу белән бәйле, муниципаль хезмәткәрләргә һәм даими нигездә муниципаль вазифаны башкаручыларга бер тапкыр түләнелә торган акчаны (единовременное поощрение) түләү турында Нигезләмә**

1.Ютазы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә һәм даими нигездә муниципаль вазифаны башкаручыларга (алга таба – муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазифаи зат) тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу белән бәйле бер тапкыр түләү (алга таба – бер тапкыр түләнелә торган акча) 2015 елның 25 июненнән булган “Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы” 50 санлы Татарстан Республикасы Законының 31 маддәсе, “Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы эшләнде.

2. Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу белән бәйле муниципаль хезмәттән киткәндә, муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәт стажы 15 ел булган очракта, муниципаль вазифасында эштән азат ителгән көненә ай саен түләнелгән хезмәт хакының биш тапкыр арттырылгын күләме, шулай ук бу чордан артып китсә, өстәмә рәвештә һәр ел өчен хезмәт хакының 0,5е күләмендә, әмма муниципаль хезмәткәрнең ун тапкыр арттырылган хезмәт хакыннан күбрәк булмаган дәрәҗәдә бер тапкыр акча түләнелә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль вазифаи затның эштән азат ителү көненә кадәр исәпләнә.

Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу дигән сүзләр астында муниципаль хезмәттән картлык буенча хезмәт пенсиясен алуга хокук биргән яшькә җитеп эштән азат ителү яки 2001 елның 17 декабреннән булган “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында”гы 173 санлы Федераль законга ярашлы, тиешле хезмәт еллары эшләгән өчен мөһим булган стаж булуы белән бергә инвалидлык буенча пенсия билгеләнүен аңларга кирәк.

3. Бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү карары, Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең һәм муниципаль вазифаи затның тиешле хезмәт еллары буенча пенсиягә чыгу турында карар кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр түләнелә торган акча, муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифаи зат турыдан-туры эштән азат ителер алдыннан, ул хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең һәм муниципаль вазифаи затның эштән азат ителгән көненнән (азаккы эш көненнән) соңламыйча, түләнелә.

5. Муниципаль хезмәткәрнең бер тапкыр түләнелә торган акчасы күләмен билгеләү өчен Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

- муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы турында белешмә;

- муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте имзалаган белешмә;

- кадрлар хезмәте имза куеп раслаган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

- чин классы, муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакына кергән вазифаи окладка өстәмәләр билгеләү турында боерыклардан (күрсәтмәләрдән) өземтәләр;

-муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен закончалыкка ярашлы мөһим булган башка документлар.

6. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктына ярашлы, җирле үзидарә органы документларны, муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазифаи зат пенсиягә эштән азат ителеп тиешле еллар эшләү сәбәпле китүгә кадәр 30 календарь көн алдан алып килә.

7. Бер тапкыр түләнелә торган акча күләмен билгеләгәндә, айлык хезмәт хакы составына түбәндәгеләр керә:

- вазифаи оклад;

-чин классы өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә;

- муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә.

8. Ютазы муниципаль районы финанс-бюджет палатасы, җирле үзидарә органы тарафыннан документлар алып киленү вакытыннан исәпләп, 20 көн дәвамында аңа бюджет ассигнованиеләре һәм муниципаль хезмәткәргә,

муниципаль вазифаи затка түләү өчен бюджет бурычлары лимитлары турында белдерә яки бер тапкыр түләнү өчен акча булмавы турында дәлилле баш тарту белдерә.

Ютазы муниципаль районы финанс-бюджет палатасы бер тапкыр түләнелә торган акчаны бирүдән, әгәр дә әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган барлык документлар да алып киленмәгән очракта баш тартырга мөмкин.

9. Җирле үзидарә органы, югарыда әйтелгән белдерүләр нигезендә муниципаль хезмәткәргә, муниципаль вазифаи затка бер тапкыр түләнелә торган акчаны түли.

10. Бер тапкыр түләнелә торган акча бер генә тапкыр түләнелә һәм бу турыда хезмәт кенәгәсендә языла. Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыккан гражданин яңадан муниципаль хезмәткә эшкә урнашса һәм аннары муниципаль хезмәттән китсә, бер тапкыр түләнелә торган акча башкача түләнелми.